**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КАРАТУН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАРЫ

12 октябрь 2018 ел №20

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Каратун авыл җирлеге Башкарма комитетың 2015 елның 13 июлендәге 08 номерлы “Административ регламентларны раслау турында” карарын үз көчен югалткан дип тану турында**

"Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында" 2015 елның 26 декабрендәге 109-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Каратун авыл җирлеге Башкарма комитеты карар итте:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Каратун авыл җирлеге Башкарма комитетының 2015 елның 13 июлендәге 08 номерлы “Административ регламентларны раслау турында” карарын көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, авыл җирлегенең максус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының рәсми сайтында җирлек бүлегендә бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Җирлек башлыгы** **Р.Р.Сабирҗанова**